# ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау исемендәге авыл җирлегенең Әхмәтовка торак пунктында 2026 елда гражданнарга үзара салым кертү турында

**2025 елның 12 ноябре** **№ 3**

Россия Федерациясенең 2025 елның 20 марты № 33-ФЗ «Бердәм җәмәгать хакимияте системасында җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законының 45 нче, 69 нчы маддәләре нигезендә, "Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлеге" муниципаль берәмлегенең Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Әхмәтовка торак пунктында гражданнар җыены

**КАРАР ЧЫГАРДЫ:**

1. 2026 елда Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Бикбау авыл җирлегенең Әхмәтовка торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган һәр кешедән 2000 сум күләмендә үзара салым кертергә.

2. Алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлтергә:

- Мәдәни мирас объектлары (Россия Федерациясе халыкларының тарих һәм мәдәният һәйкәлләре) булмаган һәйкәлләрне урнаштыру, ремонтлау һәм аларга якын территорияне төзекләндерү (Куян торак пунктында Бөек Ватан сугышында һәлак булганнарга һәйкәл урнаштыру, килешү буенча эшләр һәм хезмәтләр өчен түләү).

3.Әлеге карарны Бикбау авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында урнаштыру юлы белән халыкка җиткерергә, Минзәлә муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга (http:// menzelinsk.tatarstan.ru), рәсми хокукый мәгълүмат сайтында (http://pravo.tatarstan.ru) кабул ителгәннән соң 10 көн эчендә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Минзәлә муниципаль районы
Бикбау авыл җирлеге башлыгы____________________Л. Н. Мәрдәмшина